1 нче Нәтиҗә

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре хакында

Тойгуҗа а. 2020 елның 30 августыннан

Гавами тыңлаулар 13 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Тойгуҗа авыл җирлеге, Тойгуҗа авылы, Үзәк урамы, 48 й., Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты бинасының актлар залы.

Гавами тыңлаулар предметы: Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» «Рөхсәт ителгән күчемсез милекне файдалануның төп төрләре: - йорт яны җир кишәрлекләре булган индивидуаль торак йортлар; - шәхси торак төзелеше өчен; - шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт яны җир кишәрлеге); - участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары; - балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбиянең башка объектлары; - башлангыч һәм урта мәктәпләр.» белән карар проекты буенча фикер алышу.

Гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырлган.

2020 елның 29 июленнән 2020 елның 30 августына кадәр югарыда күрсәтелгән проект буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

2020 елның 30 августында гавами тыңлаулар уздырганда гавами тыңлауларда катнашучылардан кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәре:

1. Югарыда күрсәтелгән проект буенча бирелгән материалларны карап, гавами тыңлаулар беркетмәсе, гавами тыңлауларда катнашучыларның кисәтүләре һәм тәкъдимнәрен карап, гавами тыңлаулар үткәрү процедурасы үтәлгән һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм муниципаль хокукый актлар таләпләренә туры килә дип санарга. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы карар проектын карау буенча гавами тыңлаулар ҮТКӘРЕЛДЕ дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә тәкъдим итәргә:

3 өлешнең II бүлегендәге 35 статьясында «Ж1» бүлегенең 2 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милектән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- участоклары булган блокланган бер гаилә йортлары;
- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбия бирүнең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр.»

3. Әлеге Нәтиҗәне Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Кушымта:

2020 елның 30 августыннан гавами тыңлаулар Беркетмәсе.

Рәис Р.А. Сафин

Секретарь Г.Г. Гайфетдинова